ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 21 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 1, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) урманнардан файдалануны гамәлгә ашыручы гражданнар, юридик затлар тарафыннан тапшырылган урманнардан файдалану турындагы хисапларны карау;»;

2) 6 пунктка «урманнарны» сүзеннән соң «янгыннардан» сүзен өстәргә;

3) түбәндәге эчтәлекле $6^2$ пункт өстәргә:

«$6^2$) урманнарны пычранудан һәм башка тискәре йогынтыдан саклау чараларын гамәлгә ашыручы гражданнар, юридик затлар тарафыннан тапшырылган урманнарны пычранудан һәм башка тискәре йогынтыдан саклау турындагы хисапларны карау;»;

4) 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) урманнарны торгызуны һәм урманнар үрчетүне гамәлгә ашыручы гражданнар, юридик затлар тарафыннан тапшырылган урманнарны торгызу һәм урманнар үрчетү турындагы хисапларны карау;».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 05 апрель
№ 19-ТРЗ